СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 3-10 от «15» декабря 2021 г.

Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 182 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «11 163» санын «11 498» санына алмаштырырга;

1.2. 1 кушымтаның 3 пунктындагы 6 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмкәрне элек биләгән хезмәт вазыйфасыннан муниципаль вазыйфаның югары төркеменә керүче муниципаль хезмәт вазыйфасына күчергәндә, үзе биләгән вазыйфалары төркеме өчен беренче класслы чин бирүгә кадәр аның оклад күләмен аның биләгән вазыйфасы кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класслы чин бирелгәнче, вазыйфаи окладка карата процент ставкасыннан чыгып, 3 процентка тигез итеп исәпләнә.»

000118

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының элек биләгәннән түбән төркеменә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, муниципаль хезмәткәр элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфаларының түбән төркеменә караган һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа класслы чин бирелгән булса, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү вазыйфаи окладның 7 процентына тигез булган процент ставкасыннан чыгып башкарыла.»;

1.3. 1 нче кушымтаның 3 пунктындагы 9 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә (1 кушымта);

Әлеге карарга 5 һәм 6 нчы кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлеп килә).

1.4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендәге http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет, икътисадый сәясәт һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының
15.12.2021ел, № 3-10
карарына
1 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладына дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен айлык процентлы өстәмәләр түләү яңа редакциядә**

1. Муниципаль хезмәткәргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмәләр түләнә, Муниципальному служащему выплачивается ежемесячная процентная надбавка к должностному окладу за работу со сведениями, составляющими государственную тайну, ә дәүләт серен (махсус часть) яклау буенча структур бүлекчә хезмәткәрләренә дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эш иткән өчен вазыйфаи окладка айлык процент өстәмә рәвештә дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен вазыйфаи окладка процент өстәмәсе түләнә.

| Айлык процентлы өстәмә | Өстәмә түләү күләме (вазыйфаи окладка карата процентларда) |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән өчен | 50,0-75,0 |
| Серлелек дәрәҗәсе «тулысынча яшерен» булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 30,0-50,0 |
| Тикшерү чараларын үткәрүгә рөхсәт рәсмиләштергәндә «яшерен» серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүматлар белән эшләү өчен<br>тикшерү чаралары үткәрмичә | 10,0-15,0<br>5,0-10,0 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен:<br>1 елдан 5 елга кадәр<br>5 елдан 10 елга кадәр<br>10 елдан алып һәм күбрәк | <br>10,0<br>15,0<br>20,0 |

5 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 19.04.2018ел, №3-25
(Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Советының
15.12.2021ел, № 3-10 карары
редакциясендә)

Мамадыш муниципаль районында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфаның атамалары | Айлык акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 группа* |
| муниципаль берәмлек башлыгы | 30 442 |
| муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 27 398 |
| Депутат | 14 927 |
| җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи әгъзасы | 12 684 |
| контроль-хисап органы рәисе | 27 398 |

* Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 нче карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме

6 нчы кушымта
Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының 19.04.2018ел, №3-25
(Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Советының
15.12. 2021ел, № 3-10 карары
редакциясендә)

Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгына, Татарстан Республикасы шәһәр һәм авыл җирлекләрендә җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа исеме | айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) | | |
|---|---|---|---|
| | район әһәмиятендәге шәһәр нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләрендә | Авыл җирлекләрендә | |
| | 7 группа | 11 группа | 12 группа |
| муниципаль берәмлек башлыгы | 24 381 | 17 253 | 15 759 |
| муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 21 803 | 12 398 | 11 499 |
| Депутат | 12 348 | 11 498 | 11 498 |
| җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи әгъзасы | 11 498 | 11 498 | 11 498 |

* Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 19 апрелендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы 3-25 нче карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек керә торган хезмәт өчен түләү төркеме